| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**«Россия 2018» Республика оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия 2018» Республика оештыру комитеты эшчәнлеген камилләштерү максатларында, шулай ук кайбер затларның башка эшкә күчүләре һәм вазыйфалар атамалары үзгәрүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Россия 2018» Республика оештыру комитетын төзү турында» 2013 елның 20 мартындагы ПУ-239 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 17 маендагы ПУ-482 номерлы, 2015 елның 18 февралендәге ПУ-157 номерлы, 2015 елның 31 июлендәге ПУ-690 номерлы, 2015 елның 23 октябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2016 елның 3 февралендәге ПУ-75 номерлы, 2016 елның 13 октябрендәге ПУ-918 номерлы, 2017 елның 27 гыйнварындагы ПУ-67 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-457 номерлы һәм 2017 елның 21 июлендәге ПУ-652 номерлы указлары белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә) расланган «Россия 2018» Республика оештыру комитеты (алга таба – Комитет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комитет составыннан А.Ю. Вафинны, А.А. Здуновны, А.М. Сибагатуллинны, Э.Н. Фәттаховны, М.З. Шакировны чыгарырга;

б) Комитет составына кертергә:

Әюпова Ирада Хафизҗан кызын – Татарстан Республикасы мәдәният министрын;

Гобәйдуллин Әгъзам Самат улын – Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисен (килешү буенча);

Гомәров Рөстәм Фәрит улын – Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Садыйков Марат Наил улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын;

Шадриков Александр Валерьевичны – Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрын;

в) Комитет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ф.С. Габделганиевның – «Татарстан Республикасы икътисад министры»;

Р.Т. Борһановның – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры»;

Л.Р. Фазлыеваның – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 11 май
№ ПУ-366